ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗƏЛƏ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРЫС АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423706,Республика Татарстан
Мензелинский район, д. Урусово, ул.
Дружбы, 42

423706, Татарстан Республикасы,
Минзәлә районы,Урыс авылы, Дружбы урамы,42

телефон: (85555) 2-79-86.
EmailUrus.Mnz@tatar.ru

ОКПО 93067310 ОГРН 1061682001710 ИНН/КПП 1628006479/162801001

Минзәлә муниципаль районының
Урыс авыл җирлеге Башкарма комитеты
Карары

от «27» март 2020 ел. №6

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Урыс авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында”гы 23-ЗРТ номерлы Законы, Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карар рәсми төстә басылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә йөклим.

Авыл җирлеге башлыгы Мәүлин Ф.М..

ТР Минзәлә муниципаль районы
Урыс авыл җирлеге Башкарма комитеты
Карарына 1 нче кушымта
Дата27.03. 2020 ел. N6

## ТР Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарга үзара салым акчаларын түләтү 18 яше тулган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, 1 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, биш һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүчеләрдән, балачак инвалидларыннан тыш), Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә, 31 мартка кадәр срокта башкарыла.

3.Җитди сәбәпләр, ягъни авыру хэм озакка сузылган командировкада булганда өч айдан артмаган срокка гариза нигезендә гражданнарга түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр язуы (уведомление) бланкы Җирлекнең мәгълүмати стендында, Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең menselinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында бастыру, шулай ук имза куйдырып тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән гражданнарга җиткерелә.

5. Хәбәр язуында (уведомление) гражданнарның үзара салым акчаларын кертүгә түләү реквизитлары, тулысынча яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү күләме, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш (Кушымта).

6. Гражданнарның үзара салымнан кергән акчалата чаралары Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең лицевой счетына керә.

7. Гражданнардан түләү алу почта (хисап оешмалары) переводларын башкаруга физик затларның йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар, Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша акчаларны күчерү юлы белән башкарыла.

8. Касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслаучы булып тора.

9. Билгеләнгән срокта гражданнардан алынмаган үзара салым акчалары законда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

2 нче кушымта

ХӘБӘР ЯЗУЫ (УВЕДОМЛЕНИЕ) N _____________ Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү кертү турында

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. ________________________________________________

Адресы: _______________________________________________________

_______________________________________________________ нигезендә

Сезгә ___________ срокка кадәр ______________________ чараларны гамәлгә

_______________________________________ ашыруга бер тапкыр түләү кертергә кирәк.

суммада ______________ сум, түбәндәге реквизитлар буенча:__________________

Түләү алучы банкның БИК __________________________________________
Сч. N ___________________________________________________________
Кабул итүче Сч. N ______________________________________________
КПП ____________________________________________________________
КБК ______________ ОКАТО _______________
Түләү билгеләнеше _______________________________________________
Җитәкче _____________________________________________________
М.У. (имза) (тулысынча имза)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәр язуы (Уведомление) N ____________
Үзара салым буенча бюджетка бер тапкыр түләү кертү турында ______________
________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек атамасы)
суммада _______________ сум.

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. _____________________________________________
Адресы: ________________________________________________________
Алдым "___" ____________ 20___ ел.

____________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Хәбәр язуы төпсәсе (корешок) тутырыла һәм хәбәр язуы түләүченең шәхсән үзенә тапшырылган очракта, Башкарма комитетта кала.